**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**«ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«6» апрель 2015 ел № 36/10


**Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеген раслау турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеген 1 кушымта нигезендә расларга.
2. Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләүне билгеләү тәртибен 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Тукай муниципаль районы Советының 2011 елның 30 ноябрендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 8/7 номерлы караы үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе



В.Г. Хаҗиев